КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2026 ел, 11 май | г.Казань | № 686

Халыкара икътисадый форум уздыру чорында Казан шәһәре чикләрендә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, саммитны уздыру чорында кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казансу елгасының 3 нче транспорт дамбасыннан алып Киров дамбасына кадәр участогында 2026 елның 11 маеннае 18 маена кадәр, 06.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр чорда аз үлчәмле судноларны, шулай ук җилкәнле, йөрүче, спорт судноларын, гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрен дә кертеп, куллануны тыю билгеләргә (алга таба - тыю).

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкка тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә ёщм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин